| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2022 елның 30 июне № 20/5

Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи үз-үзләрен тотышына карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

РФ Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы, 2022 елның 6 июнендәге коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2018 елның 16 августындагы 28/5 номерлы карары (25.03.2020 № 44/2, 03.06.2020 № 45/7 редакциясендә) белән расланган Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи үз-үзләрен тотышына карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы Нигезләмәнең 3.2.5 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты,» сүзләреннән соң «комиссия» сүзен «Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру-кадрлар эше һәм эш башкару бүлеге башлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

«һәм кызыксынган оешмалар,» сүзләреннән соң ««Посейдон» коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын куллану, шул исәптән запрослар җибәрү өчен» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе А.М. Хасановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров